# СӨМБЕЛ

*Әхмәт Ерикәй сүзләре*









Ак калфагың чиккән, бөккән,  
Ука белән чукланган. } 2 тапкыр  
Ай Сөмбел, вай Сөмбел (лә),  
Сөйгәнемне үзең бел!

Илнең матур егетләре  
Ай йөзенә сокланган. } 2 тапкыр  
Ай Дилбәр, вай Дилбәр,  
Күңлең күктәй киң, диләр.

Кәмәр буган, матур булган  
Кайсы илнең баласы? } 2 тапкыр  
Ай иркәм, вай иркәм,  
Сөйгән егетең кем икән?

Ак калфагын кыңгыр салган  
Кайсы егет җанашы. } 2 тапкыр  
Ай чәчәк, вай чәчәк,  
Матур исемең чәчеләчәк.

Синнән матур кызлар юк, дип,  
Исемең илгә чәчеләчәк.